**2023 елның 1 яртыеллыгында Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү турында мәгълүмат**

2023 елның 1 яртыеллыгында шәһәрнең җирле үзидарә органнарында гражданнар тарафыннан язмача җибәрелгән һәм шәхси кабул итүдә бирелгән **3870** мөрәҗәгать карап тикшерелде (2022 елда – 4122).

Мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан:

**2340ы** – язмача мөрәҗәгать (2022 елда – 2680), шул исәптән 1552се электрон документ рәвешендә алынган.

Шәһәр Хакиме һәм Башкарма комитет Җитәкчесе адресына 4865 мөрәҗәгать итүчедән 113 коллектив мөрәҗәгать керде.

2340 мөрәҗәгатьнең 461е уңай хәл ителде, бу гомуми санның 19,7 % ын тәшкил итте, 105е ведомстволарга адресланды, калган мөрәҗәгатьләр буенча аңлатмалар һәм рекомендацияләр бирелде.

Үзләренең социаль хәлен күрсәткән мөрәҗәгать итүчеләр составында түбәндәге категориягә ия гражданнар бар:

- эшләүчеләр: 161 (6,88 %);
- пенсионерлар: 112 (4,79 %);
- эшмәкәрләр: 39 (1,67 %);
- интеллигенция: 33 (1,41 %);
- хезмәткәрләр: 26 (1,11 %);
- хуҗабикәләр: 25 (1,07 %);
- эшсезләр: 12 (0,51 %);
- укучылар: 1 (0,04 %);
- социаль хәлен күрсәтмәүчеләр: 1931 (82,52 %).

Мөрәҗәгать итүчеләр арасында үзенең льготалы категориягә ия булуын күрсәткән гражданнарның күпчелеге: күп балалы гаиләләр – 67 (2,86 %), инвалидлар – 55 (2,35 %), хәрби хәрәкәт ветераннары – 11 (0,47 %), качаклар – 4 (0,17 %).

Гражданнардан кергән язмача мөрәҗәгатьләрне анализлау шуны күрсәтә, шәһәрдә яшәүчеләр өчен 2023 елның 1 яртыеллыгында түбәндәге мәсьәләләр актуальрәк саналган:

- торак-коммуналь хуҗалыгы – 832 (2022 – 1007);
- юл хуҗалыгы – 239 (2022 – 278);

- җирдән файдалану – 158 (2022 – 223);
- мәгариф һәм мәктәпкәчә тәрбия – 146 (2022 – 153);
- торак өлкәсе – 127 (2022 – 142);
- транспорт хезмәте күрсәтү – 114 (2022 – 85);
- төзелеш – 139 (2022 – 191);
- сәламәтлек саклау – 95 (2022 – 81);
- социаль тәэмин итү – 106 (2022 – 137);
- финанс өлкәсе – 54 (2022 – 55);
- законлылык һәм хокук тәртибен тәэмин итү – 67 (2022 – 60);
- сәүдә һәм куллланучылар хезмәте – 78 (2022 – 107);
- РФ Кораллы Көчләрендә хезмәт итү мәсьәләләре – 42 (2022 – 1);
- хезмәт һәм мәшгульлек – 26 (2022 – 38);
- элемтә мәсьәләләре – 24 (2022 – 33);
- башкалар – 93 (2022 – 89).

Гражданнарның дәүләт органнары белән уңайлы аралашу чарасы булып шәхси кабул итүләр тора. 2023 елның 1 яртыеллыгында **1530** чаллылы кабул итүнең шул формасыннан файдаланган (2022 – 1442).

511 мөрәҗәгать буенча кирәкле чаралар күрелде, мөрәҗәгать иткән 1000 гражданга тиешле аңлатмалар бирелде, 19 мөрәҗәгать контрольдә тора.

Шәһәр Хакиме һәм Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан турыдан-туры 128 чаллылы кабул ителде.

Гражданнарны кабул итү һәр атнаның сишәмбе көннәрендә гамәлгә ашырыла:

- район хакимиятләре Башлыклары тарафыннан (район хакимиятләренең урнашу урыны буенча), 14.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр;
- Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарлары, идарә башлыклары тарафыннан, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт адресы буенча урнашкан хакимият бинасында, 14.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр;
- шәһәр Хакиме, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан, Академик Рубаненко бульвары, 7 йорт адресы буенча урнашкан шәһәр Хакименең җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәсе бинасында, 16.00 дән 18.00 сәгатькә кадәр;
- шәһәр Хакиме ярдәмчесе (халык белән эшләү буенча) тарафыннан Академик Рубаненко бульвары, 7 йорт адресы буенча урнашкан шәһәр Хакименең җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәсе бинасында, шимбә һәм

якшәмбедән кала һәр көнне 08.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш вакыты 12.00 дән 13.00 гә кадәр.

Җирле үзидарә органнарында гражданнардан кергән бер генә мөрәҗәгать тә игътибарсыз калмый.

Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрнең мониторингы көн саен үткәрелә, мөрәҗәгатьләрне үз вакытында карап тикшерү контрольдә тотыла, үтәү дисциплинасына анализ ясала.

Гражданнар мөрәҗәгатьләрендә бәян ителгән мәсьәләләр компетенция кысаларында оператив рәвештә хәл ителә.

Мөрәҗәгать итүче һәркемгә гамәлдәге законнар нигезендә язмача җавап һәм аңлатма бирелә.